КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 6 апрель г.Казань № 316

Яшьләр сәясәте өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең муниципаль автоном һәм бюджет яшьләр сәясәте учреждениеләренә грантлар турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (декабрьга теркәләләр) расларга:

Яшьләр сәясәте өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең муниципаль автоном һәм бюджет яшьләр сәясәте учреждениеләренә грантлар турында нигезләмә (алга таба - Нигезләмә);

Яшьләр сәясәте өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең муниципаль автоном һәм бюджет учреждениеләренә грантлар түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе.

2. Әлеге карар, 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган Нигезләмәнең 6.1 пунктындагы икенче абзацыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин